КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1172

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2017 – 2021 елларга» сүзләрен «2017 – 2024 елларга» сүзләренә, «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру, бетерелү, банкротлык процессында булмаска тиеш, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга тиеш, индустриаль паркның идарә итүче компаниясе эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;»;

җиденче абзацта «билгеләнгән күрсәткечләрнең мәгънәләренә тигез һәм (яки) алардан артып киткән» сүзләрен «билгеләнгән таләпләргә туры килә торган» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәге күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать мәйданчыклары төзү һәм үстерү» ярдәмче программасы белән каралган таләпләргә туры килергә тиеш:

резидентларның җыелма табышы;

булдырылган эш урыннары саны;

резидентлар саны;

җыелма өстәлгән кыйммәт.»;

8 нче пунктта:

беренче абзацта «18 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «27 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«идарә итүче компания җитәкчесе тарафыннан идарә итүче компаниянең үзгәртеп оештыру, бетерелү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәве, индустриаль паркның идарә итүче компаниясе эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы турындагы белешмә кәгазен;»;

сигезенче абзацка «кабул итү-тапшыру актлары күчермәләрен» сүзләрен өстәргә;

унсигезенче абзацта «билгеләнгән күрсәткечләрнең мәгънәләренә тигез һәм (яки) алардан артып киткән» сүзләрен «билгеләнгән таләпләргә туры килә торган» сүзләренә алыштырырга;

14 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә субсидия күләме; аның максатчан билгеләнеше; чыгымнарның аны каплау өчен субсидия бирелә торган юнәлешләре; субсидияне күчерү вакытлары һәм тәртибе; субсидия күчерелә торган счетлар; субсидияләр бирү нәтиҗәләре мәгънәсе; түбәндәге хисап документларын теркәп, субсидияне файдалану һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап документларын тапшыру вакытлары һәм формалары: дәүләт төзелеше күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүе-килмәве турындагы бәяләмәсе һәм субсидияләнә торган объектны файдалануга тапшыру акты; субсидияне кире кайтару очрагы; идарә итүче компаниянең һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы; бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр; идарә итүче компаниянең кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән, шулай ук субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган өчен җаваплылыгы; субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгәндә кулланыла торган штраф санкцияләре карала.»;

17 нче пунктта «нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәү» сүзләренә алыштырырга;

18 нче пунктта «Министрлык» сүзеннән соң «субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә» сүзләрен өстәргә;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Субсидияләр алучылар Министрлыкка, хисап елыннан соң килүче елның 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтагы форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык кертә.

Әгәр дә идарә итүче компания килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешә алмаган булса, Министрлык штраф санкцияләрен куллана. Бу очракта штраф санкцияләренең (А) күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A=\left(\sum_{i=1}^{4}\left(1-\frac{d_i}{D_i}\right)\times X\right)\times V,$$

монда:

i – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$d_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирүнең i-нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

$D_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирүнең i-нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе;

X –хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкындагы төп ставканың $\frac{1}{300}$ тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – идарә итүче компания тарафыннан алынган субсидия акчасының күләме.

Әгәр дә субсидия бирү нәтиҗәләренең берсен исәпләгәндә факттагы мәгънәсе план буенча мәгънәсеннән артып китсә, бу нәтиҗә буенча $\left(1-\frac{d_i}{D_i}\right)$ формуланың мәгънәсе нульгә тигез итеп алына.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20___ елның «___» ____________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
хисап

Субсидия алучының исеме ________________________________________
Дәвамлылык: ел саен

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Субсидия алучының
җитәкчесе (вәкаләтле зат) _______________ ____________ __________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны тулысынча язу)

Үтәүче __________________ _____________________ ___________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис.) (телефоны)

20__ ел, «____»___________

___________________________